| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2026 Казан ш № 495

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге 701-ПУ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биләгән вакытта үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук керемнәре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында», 2009 елның 30 декабрендәге 702-ПУ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында» 16.07.2018 ел, № 560 боерыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.07.2018 № 560 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле булган, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында,» 20.10.2020 ел, № 739 боерыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.07.2018 № 560 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында биләве коррупция куркынычы белән бәйле булган, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәти характердагы йөкләмәләретурында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 12.07.2021 ел, № 484 боерыгы ;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 6 июлендәге 454 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренә Рәсәй Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» боерыгына үзгәреш кертү турында» 14.03.2023 ел, № 164 боерыгы ;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгының 16.07.2018 № 560 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында бирергә тиеш

булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 14.03.2024 ел, № 170 боерыгы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау Министрлыгының 16.07.2018 № 560 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, И хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 05.08.2024 ел, № 547 боерыгы

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының « 26 » 06 2026 № 495 номерлы боерыгы белән расланган

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Вазыйфаларның югары төркеменең «Җитәкчеләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары.

2. Вазыйфаларның әйдәп баручы төркеменең “Ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары вазыйфаларының баш төркеменең «җитәкчеләр» категориясе:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының эшләр идарәчесе (алга таба - Министрлык);

юридик бүлек башлыгы;

Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы;

Министрлыкның массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы;

Министрлыкның координация һәм контроль бүлеге башлыгы;

Министрлыкның хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе бүлеге башлыгы;

Министрлыкның тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның контроль-ревизия эше бүлеге башлыгы;

Министрлыкның планлаштыру, финанслау һәм хезмәт өчен түләү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның дәүләт сатып алулары бүлеге башлыгы;

Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге башлыгы;

Министрлыкның социаль регистрын формалаштыру бүлеге башлыгы;

Министрлыкның социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы;

Министрлыкның тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә һәм пенсиягә өстәмә билгеләү һәм түләү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның актив мәшгульлек сәясәте чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

Министрлыкның хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы;

Министрлыкның хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне мониторинглау бүлеге башлыгы;

Министрлыкның һөнәри белем бирү һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның чаралар үткәрүне оештыру бүлеге башлыгы;

министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлеге башлыгы;

министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге башлыгы;

министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы;

министрлыкның тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны эксплуатацияләү, мәгълүмати иминлекне тәэмин итү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы;

Министрлыкның махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

Министрлыкның иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлеге башлыгы;

административ-хуҗалык бүлеге башлыгы;

эш башкару бүлеге башлыгы;

Министрлыкның муниципаль районында (шәһәр округында) социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «җитәкчеләр» категориясе:

Министрлыкның халык белән эшләү секторы мөдире;

Министрлыкның мобилизацион әзерлек һәм гражданнар оборонасы секторы мөдире;

Министрлыкның юридик бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның координация һәм контроль бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның хезмәтне планлаштыру, финанслау һәм түләү бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль регистрын формалаштыру бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль ярдәм чараларына аудит бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның актив мәшгульлек сәясәте чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне мониторинглау бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның һөнәри белем бирү һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү, мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары.

5. Вазыйфаларның әйдәп баручы төркеменең «белгечләр», «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә - Министрлык буйсынуындагы учреждениеләрдә хезмәт законнары таләпләренең һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның бүлек компетенциясе чикләрендә үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыруда катнашуны күздә тоткан әйдәп баручы киңәшче; коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы әйдәп баручы белгеч;

хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлегендә - әйдәүче киңәшче;

юридик бүлектә - вазыйфаи бурычларын үтәве Административ хокук бозулар турында Рәсәй Федерациясе Кодексының 19.7, 13.11[1] статьялары һәм 5.42 статьясындагы 1 өлеше буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүдә катнашуны күздә тоткан әйдәүче киңәшче, әйдәүче консультант;

хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе бүлегендә - вазыйфаи бурычларын үтәү Рәсәй Федерациясе Хезмәт Кодексының 213 статьясы нигезендә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрүне, дәүләт контрактлары (шартнамәләре)төзү эшләрен күздә тоткан әйдәүче белгеч, әйдәүче консультант;

социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч;

мәшгульлекнең актив сәясәте чараларын гамәлгә ашыру бүлегендә - әйдәүче киңәшче, әйдәүче консультант;

хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне мониторинглау бүлегендә - әйдәүче киңәшче, әйдәүче консультант;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларның социаль интеграциясе бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

мәгълүмати технологияләр, автоматлаштырылган системаларга техник хезмәт күрсәтү һәм аларны эксплуатацияләү, мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү бүлегендә - әйдәп баручы белгеч;

планлаштыру, финанслау һәм хезмәткә түләү бүлегендә - әйдәп баручы белгеч;

контроль-ревизия эше бүлегендә-әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч, 1 разрядлы белгеч;

дәүләт сатып алулары бүлегендә - әйдәүче белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

социаль регистрны формалаштыру бүлегендә - әйдәүче киңәшче;

социаль ярдәм чараларының аудиты бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч;

тиешле еллар эшләгән өчен пенсия һәм пенсиягә өстәмә билгеләү һәм түләү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

һөнәри белем бирү һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче;

хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч, әйдәп баручы консультант;

чараларны үткәрүне оештыру бүлегендә - әйдәүче белгеч;

социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлегендә - әйдәүче киңәшче;

социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлегендә - әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт;

иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлегендә - әйдәүче киңәшче;

административ-хуҗалык бүлегендә - 1 разрядлы өлкән белгеч;

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегендә - әйдәүче белгеч, әйдәүче консультант, 1 разрядлы өлкән белгеч;

Министрлыкның муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсендә (бүлегендә) - консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт.